**СОВЕТ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

**Татарстан Республикасы**

**Яңа Чишмә муниципаль районы Советы**

# КАРАРЫ

**2016 елның «11» августыннан** **№ 17-73**

**«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2015 елның 18 мартындагы 42-247 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» карар проекты хакында**

«Яңа Чишмә муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы турында нигезләмә хакында» 2005 елның 30 декабрендәге 5-37 номерлы Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы карарына, «Яңа Чишмә муниципаль районының финанс-бюджет Палатасы турында нигезләмә хакында» Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2013 елның 07 августындагы 25-164 номерлы карарына, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2011 елның 20 декабрендәге 9-75 номерлы карары белән туры китерү максатларында Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2015 елның 18 мартындагы 42-247 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

- «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге уставының 56 статьясын яңа редакциядә бәян итәргә:

«1. Районның Контроль-хисап Палатасы җирле үзидарәнең даими эшләүче, коллегиаль финанс контроле органы булып тора.

2. Районның Контроль-хисап Палатасы рәис һәм аудиторлардан тора.

Оештыру һәм эшчәнлек тәртибе, районның Контроль-хисап Палатасы вәкаләтләре Россия Федерациясе Бюджет кодексы белән «Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнарын оештыруның һәм аларның эшчәнлегенең гомуми принциплары турында» 2011 елның

7 февралендәге 6-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, башка федераль законнар һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, район Советы, башка муниципаль норматив хокукый актлар белән расланган район Контроль-хисап Палатасы турындагы Нигезләмә белән билгеләнә.

Федераль законнарда билгеләнгән очракларда һәм тәртиптә, районның Контроль-хисап Палатасы эшен һәм эшчәнлеген хокукый җайга салу шулай ук Татарстан Республикасы законнары белән гамәлгә ашырыла.

3. Җирле үзидарә органы вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда районның Контроль-хисап Палатасы район Советына хисап бирәчәк.

2. Районның Контроль-хисап Палатасы рәисе район башлыгы тәкъдиме белән район Советы вазыйфасына билгеләнә. Районның Финанс-бюджет Палатасы рәисе вазыйфасына Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләт биргән Федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнгән квалификация таләпләренә җавап бирүче затлар билгеләнә.

- «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге уставының 57 статьясын яңа редакциядә бәян итәргә:

«1. 1. Районның Финанс-бюджет Палатасы җирле үзидарәнең даими эшләүче финанс органы булып тора, ул җирле үзидарәнең даими эшләүче органы булып тора:

- район бюджеты проектын төзү (бюджет проекты һәм уртача вакытка исәпләнгән финанс планы);

- район бюджеты проектын (бюджет проекты һәм уртача вакытка исәпләнгән финанс планы) кирәкле документлар һәм материаллар белән район башкарма комитетына раслау өчен район Советына кертү;

- район бюджеты үтәлешен оештыру;

- бюджет хисабын төзү тәртибен билгеләү;

- җирле үзидарә финанс органының Россия Федерациясе Бюджет кодексында һәм (яисә) аның нигезендә кабул ителә торган районның бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга сала торган муниципаль норматив хокукый актларында билгеләнгән бюджет вәкаләтләре (статья 2007 елның 2 августындагы 38-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы редакциясендә).

2. Районның Финанс-бюджет Палатасы җирле үзидарә финанс органы вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда район Советына һәм Башкарма комитетына хисап тота.

3. Районның Финанс-бюджет Палатасы үз эшчәнлеген законнар, әлеге Устав һәм район Советы тарафыннан расланган Финанс-бюджет палатасы турындагы Нигезләмә нигезендә башкара.

Районның Финанс-бюджет Палатасы җитәкчесе район Башлыгы тәкъдиме белән район Советы тарафыннан билгеләнә. Районның Финанс-бюджет Палатасы рәисе вазыйфасына Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләт биргән Федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнгән квалификация таләпләренә җавап бирүче затлар билгеләнә.

4. Районның Финанс-бюджет Палатасы җитәкчесе районның җирле үзидарә вазыйфаи заты булып тора, районның финанс органы эшчәнлегенә җитәкчелек итә һәм аның эшен оештыра.

5. Район Финанс-бюджет Палатасының мөһере, район гербы төшерелгән һәм үз исеме язылган бланкасы бар.

6. Районның Финанс-бюджет Палатасы эшчәнлеген тәэмин итү чыгымнары район бюджетында Россия Федерациясе бюджетларының чыгымнары классификациясе нигезендә аерым юл белән карала.

- «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге уставының 57 статьясын яңа редакциядә бәян итәргә:

«Районның Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы үз вәкаләтләре чикләрендә муниципаль милек белән, шул исәптән район милкендә булган җир кишәрлекләре, акцияләр, хуҗалык җәмгыятьләренең устав капиталларында өлешләр (кертемнәр) белән идарә итүне гамәлгә ашыручы җирле үзидарә органы булып тора.

Районның Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә муниципаль милек реестрын алып бара.

Районның Иилек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы үз вәкаләтләрен тормышка ашырганда район Советына һәм Башкарма комитетына хисап тота.

2. Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы үз эшчәнлеген законнар, әлеге Устав һәм район Советы тарафыннан расланган Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы турындагы Нигезләмә нигезендә башкара.

3. Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе район Советы тарафыннан район Башлыгы тәкъдиме белән билгеләнә.

4. Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе районның җирле үзидарә вазыйфаи заты булып тора, Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы эшчәнлеге белән җитәкчелек итә һәм аның эшен оештыра.

5. Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасының район гербы сурәтләнгән һәм үз исеме язылган мөһер, бланклары бар.

6. Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы эшчәнлеген тәэмин итү чыгымнары район бюджетында Россия Федерациясе бюджетларының чыгымнары классификациясе нигезендә аерым юл белән карала.

2. «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2015 елның 18 мартындагы 42-247 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы карарының әлеге проектын кабул итәргә һәм халык алдында тыңлауларга чыгарырга.

3. Татарстан Республикасының Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2015 елның 18 мартындагы 42-247 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасының Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» карары проекты буенча 2016 елның 22 августында сәг. 10.00 дә Татарстан Республикасы, Яңа Чишмә районы, Яңа Чишмә авылы, Совет урамы,80 йорт адресы буенча урнашкан Яңа Чишмә муниципаль районы Советының актлар залында ачык тыңлаулар үткәрергә.

Ачык тыңлаулар үткәрү тәртибе Яңа Чишмә муниципаль районының 2006 елның 23 ноябрендәге 10-81 номерлы карары белән расланган, 2006 елның 29 ноябрендә «Яңа Чишмә хәбәрләре» район газетасының 116 номерында басылып чыккан гавами тыңлаулар турындагы Нигезләмә нигезендә башкарыла.

4. Яңа Чишмә муниципаль районы Советының оештыру бүлегенә ачык тыңлаулар үткәрүне, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы

Советының күрсәтелгән карары проекты буенча гражданнар тәкъдимнәрен кабул итүне һәм исәпкә алуны тәэмин итәргә.

5. Законлылык, хокук тәртибе һәм җирлекләрнең вәкиллекле органнары белән үзара хезмәттәшлек буенча даими комиссиягә гавәми тыңлауларда яңгыраган һәм фикер алышу барышында кергән тәкъдимнәрне исәпкә алып, Яңа Чишмә муниципаль районы Советы карары проектын эшләп бетерергә һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы утырышына кертергә.

6. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында халыкка җиткерергә (бастырып чыгарырга).

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм җирлекләрнең вәкиллекле органнары белән хезмәттәшлек буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

**Яңа Чишмә**
**муниципаль районы Башлыгы** **В. М. Козлов**